**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 ноябрь № 906

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында» 2013 ел, 22 август, 591 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт җыелма командаларын (шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында) әзерләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 27 август, 604 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче карары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының спорт җыелма командаларын (шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында) әзерләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

II бүлектә:

бишенче абзацта «25.08.2001» саннарын «20.08.2001» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары»;

алтынчы абзацны төшереп калдырырга;

III бүлекнең таблицасындагы 4 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы тарафыннан (алга таба – ТР ЯЭСһТМ)» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан (алга таба – ТР ЯЭһСМ)» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекнең 4.7 пунктында «2 нче таблица» сүзләрен «Таблица» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең 5.4 пунктында «ТР ЯЭСһТМ» сүзләрен «ТР ЯЭһСМ» сүзләренә алмаштырырга;

VI бүлекнең 6.2 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары»;

VII бүлекнең 7.1 пунктындагы, VIII бүлекнең 8.3 пунктындагы, IX бүлекнең 9.2 пунктындагы, XIII бүлекнең 13.1 пунктындагы беренче абзацта «ТР ЯЭСһТМ» сүзләрен «ТР ЯЭһСМ» сүзләренә алмаштырырга;

XII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«XII. Әлеге Стандартның сакланмавына шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) Учреждениегә язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә. Учреждение җитәкчесе кабул иткән карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына бирелә.

12.2. Шикаять почта аша, күп вазыйфалы үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Учреждениенең рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша бирелә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә тапшырылырга мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында законнар белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Шикаять теркәлгән көннән соң унбиш эш көне эчендә шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан, ә Учреждение, Учреждениенең вазыйфаи заты гариза бирүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта шикаять бирү яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять бирү аны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Учреждение дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килгән көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаять карап тикшерү нәтиҗәләре турында язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча – электрон рәвештә дәлилле җавап җибәрә.

12.6. Граждан (аның законлы вәкиле) дәүләт хезмәтен күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә судта шикаять белдерә алалар.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы, 2014 ел, 24 февраль, 118 нче, 2014 ел, 30 апрель, 284 нче, 2014 ел, 2 июнь, 374 нче, 2014 ел, 17 июнь, 418 нче, 2014 ел, 8 июль, 473 нче, 2014 ел, 9 июль, 477 нче, 2014 ел, 25 август, 612 нче, 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы, 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче, 2014 ел, 6 декабрь, 956 нчы, 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче, 2015 ел, 1 июнь, 390 нчы, 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы, 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы, 2015 ел, 28 июль, 549 нчы, 2015 ел, 16 октябрь, 770 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларына булышлык күрсәтү» ярдәмче программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары» юлында «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитны саклау, табигый байлыкларны яңадан җитештерү һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый байлыкларны яңадан җитештерү һәм файдалану» дәүләт программасына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 21 июль, 521 нче, 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче, 2014 ел, 6 декабрь, 950 нче, 2015 ел, 6 май, 329 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге дәүләт программасы паспортының «Программаның дәүләт заказчылары» юлында «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче, 2015 ел, 8 май, 333 нче, 2015 ел, 17 июнь, 444 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карарның преамбуласында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 ел, 15 май, 792-б номерлы боерыгы белән расланган «2013 – 2020 елларга мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы» һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 ел, 20 декабрь, 2433-б номерлы боерыгы белән расланган «2013 – 2020 елларга фәнне һәм технологияләрне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт

программасы» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 15 апрель, 295 нче карары белән расланган «2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы» һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 15 апрель, 301 нче карары белән расланган «2013 – 2020 елларга «Фәнне һәм технологияләрне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

паспортның «Программаның дәүләт заказчылары», «Программаның төп эшләүчеләре» юлларында, әлеге дәүләт программасының 4 бүлегендәге унынчы абзацта, әлеге дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга гомуми белем бирүне, инклюзив белемне дә кертеп, үстерү һәм әлеге тармактагы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасындагы 1 бүлекнең беренче абзацында, әлеге дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга өстәмә белем бирүне, инвалид балаларга белем бирүне дә кертеп, үстерү һәм әлеге тармактагы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасы паспортының «Программаның дәүләт заказчылары», «Программаның төп эшләүчеләре» юлларында, 1 бүлекнең таблицасында һәм таблицадан соң өченче абзацта, 2 бүлекнең 8 пунктындагы җиденче абзацта әлеге дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга һөнәри һәм югары уку йортыннан соң белем бирүне үстерү һәм әлеге тармактагы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасы паспортының «Программаның дәүләт заказчылары», «Программаның төп эшләүчеләре» юлларында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга мәктәпкәчә белем бирүне, инклюзив белемне дә кертеп, үстерү һәм әлеге тармактагы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

2 бүлектә:

1 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2011 ел, 20 июль, 2151 нче боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә белемнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыру шартларына федераль дәүләт таләпләре нигезендә» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белемнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 октябрь, 1155 нче боерыгы белән расланган мәктәпкәчә белемнең федераль дәүләт белем бирү стандартының 3.3.4 пункты нигезендә үстерүче әйбер-киңлек мохиты бай эчтәлекле, үзгәрә торган, күпвазыйфалы, вариатив, һәркем файдаланырлык һәм куркынычсыз булырга тиеш.» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүгенге көндә мәктәпкәчә белемнең төп гомуми белем бирү программасы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белемнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 октябрь, 1155 нче боерыгы белән расланган мәктәпкәчә белемнең федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә эшләнә.»;

2 бүлекнең 11 пунктын 12 пункт дип санарга;

4 бүлектә:

беренче абзацта «2013 – 2020 елларга мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013 – 2020 елларга мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 295 нче карары белән расланган «2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 ел, 19 сентябрь, 1204 нче карары белән расланган Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен белем бирү учреждениесе турында үрнәк нигезләмә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төп гомуми белем бирү программалары – мәктәпкәчә белемнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 30 август, 1014 нче боерыгы белән расланган Төп гомуми белем бирү программалары – мәктәпкәчә белемнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен саклап» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү тармагында контракт системасы турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр, хезмәтләр тармагында контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга гомуми белем бирүне, инклюзив белемне дә кертеп, үстерү һәм әлеге тармактагы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

1 бүлекнең сигезенче-унберенче абзацларын төшереп калдырырга;

2 бүлектә:

8 пунктның дүртенче абзацында «(«Мәгариф турында» 1992 елның 10 июлендәге 3266-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (2012 елның 12 ноябрендәге 185-ФЗ номеры редакциясендә) 50 статьясындагы 4 пункт» сүзләрен төшереп калдырырга;

16 пунктның унөченче абзацында «20.05.2008» саннарын «29.05.2008» саннарына алмаштырырга;

17 пунктның таблицасыннан соң сигезенче абзацта «алып барыла» сүзен «алып барылды» сүзенә, «планлаштырыла» сүзен «планлаштырылды» сүзенә алмаштырырга;

22 пунктның өченче абзацында «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү турында» сүзләрен «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга өстәмә белем бирүне, инвалид балаларга белем бирүне дә кертеп, үстерү һәм әлеге тармактагы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасының 1 бүлегендә «балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә дәресләр үткәрелә ала» сүзләрен «балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә дәресләр үткәрелә алды» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга һөнәри һәм югары уку йортыннан соң белем бирүне үстерү һәм әлеге тармактагы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасының 1 бүлегендә:

өченче абзацта «билгеләнде» сүзен «билгеләнгән иде» сүзләренә алмаштырырга;

«Һөнәри белем бирү системасы торышы» бүлекчәсендә егерме бишенче абзацта «расланды» сүзен «расланган иде» сүзләренә, «күздә тота» сүзләрен «күздә тотты» сүзләренә алмаштырырга;

егерме тугызынчы абзацта «тормышка ашырылачак» сүзләрен «тормышка ашырылды» сүзләренә алмаштырырга;

утызынчы абзацта «үз эченә ала» сүзләрен «үз эченә алды» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәрге чорда Татарстан Республикасында яшьләр иректе хәрәкәтен үстерү һәм аңа булышлык күрсәтү концепциясен раслау турында» 2014 ел, 27 февраль, 124 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елга кадәрге чорда Татарстан Республикасында яшьләр иректе хәрәкәтен үстерү һәм аңа булышлык күрсәтү концепциясенең 2 бүлегендәге өченче абзацта Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясе турында» 2006 ел, 18 декабрь, 1760-р номерлы боерыгы» сүзләрен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 29 ноябрь, 2403-р номерлы боерыгы» сүзләренә, «803» саннарын «830» саннарына алмаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында һәм олимпия резервы училищесында уку-укыту-күнегү процессын оештыру өчен спорт корылмаларын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 22 май, 345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 июль, 459 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында һәм олимпия резервы училищесында уку-укыту-күнегү процессын оештыру өчен спорт корылмаларын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлекнең 5.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «СНиП 2.09.04-87 «Административ һәм көнкүреш биналары»;

12 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Стандартның сакланмавына шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) Учреждениегә язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә. Учреждение

җитәкчесе кабул иткән карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына бирелә.

12.2. Шикаять почта аша, күп вазыйфалы үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Учреждениенең рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша бирелә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә тапшырылырга мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында законнар белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Шикаять теркәлгән көннән соң унбиш эш көне эчендә шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан, ә Учреждение, Учреждениенең вазыйфаи заты гариза бирүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта шикаять бирү яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять бирү аны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Учреждение дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килгән көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаять карап тикшерү нәтиҗәләре турында язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча – электрон рәвештә дәлилле җавап җибәрә.

12.6. Граждан (аның законлы вәкиле) дәүләт хезмәтен күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә судта шикаять белдерә алалар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\906.docx